**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 9 декабрендәге 4309 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2018 елның 2 ноябрендәге 5673 номерлы «Җәйге һәм кышкы чорда ясалма корылмаларны (күперләрне, җәяүлеләр кичүләрен, юлүткәргечләрне) карап тоту буенча финанс чыгымнары нормативлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы федераль закон һәм Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 20012 елның 16 ноябрендәге 402 номерлы «Автомобиль юлларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту буенча эшләр классификациясен раслау турында»гы әмере нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 2 ноябрендәге 5673 номерлы «Җәйге һәм кышкы чорда ясалма корылмаларны (күперләрне, җәяүлеләр кичүләрен, юлүткәргечләрне) карап тоту буенча финанс чыгымнары нормативлары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 19 декабрендәге 4477 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 2 ноябрендәге 5673 номерлы карарына кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.В.Куляжевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2023 елның 9 декабрендәге
4309 номерлы карарына
кушымта

**Җәйге һәм кышкы чорда ясалма корылмаларны (күперләрне, җәяүлеләр кичүләрен, юлүткәргечләрне) карап тоту буенча финанс чыгымнары нормативлары**

| Программа исеме | Үлчәү берәмлеге | Тариф, сумнарда |
|---|---|---|
| Җәйге чорда машина юлларын һәм җәяүлеләр тротуарларын карап тоту | Кв.м | 0,41 |
| Кышкы чорда машина юлларын һәм җәяүлеләр тротуарларын карап тоту | Кв.м | 0,90 |
| Юл киртәләрен шланг ярдәмендә тузаннан һәм пычрактан су белән юу (юл киртәләре, киртәләр, тотынгычлар) | М | 22,58 |
| Күперләрнең һәм юлүткәргечләрнең машиналар йөри торган өлешендәге су үткәргеч торбаларны кул белән чистарту | Данә | 52,16 |
| Ферма асты мәйданнарын пычрактан һәм чүп-чардан кул белән чистарту | Кв.м | 190,14 |
| Деформацияләнгән җөйләрне шланг белән басым астында юу | Җөй, м | 126,67 |
| Күпер корылмаларының керү юлларын һәм күпер асты зоналарын пычрактан һәм чүп-чардан кул белән чистарту | Кв.м | 0,48 |
| Лампалы светофор объектларын карап тоту (аена) | Данә | 2 325,7 |
| Җәяүлеләр өчен җир өсте һәм җир асты кичүләренең поликарбонат капламнарын кардан чистарту | Кв.м | 92,81 |
| Җир асты җәяүлеләр кичүләрендә яктылык нокталарын (электр энергиясеннән башка) карап тоту | Берәмлек/көнгә | 4,06 |
| Җир өсте җәяүлеләр кичүләрендә һәм тоннельләрдә яктылык нокталарын (электр энергиясеннән башка) карап тоту | Берәмлек/көнгә | 3,55 |
| Җәяүлеләр өчен җир асты һәм җир өсте кичүләренең территорияләрен себерү | Кв.м | 4,72 |

| **Программа исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **Тариф, сумнарда** |
|---|---|---|
| Җәяүлеләр өчен җир өсте һәм җир асты кичүләренең өслеген юу | Кв.м | 30,48 |
| Насос җиһазларына техник хезмәт күрсәтү | Данә | 3 022,00 |
| Идән өслекләрен юу | Кв.м | 44,05 |
| Майлы буяулар белән буялган стена һәм фасад өслекләрен юу | Кв.м | 44,05 |
| Конструкция элементларын игъланнардан чистарту | Кв.м | 144,86 |
| Өслекләрне тотрыклы химик пычранулардан чистарту | Кв.м | 2 718,65 |
| Барьер киртәләрен һәм яктылыкны кире кайтара торган элементларны кардан һәм пычрактан кул белән чистарту | М | 5,05 |
| Катнаш төрдәге юл машиналары җайланмаларын (ян-якка урнаштырыла торган щетка) кулланып, коймаларны кардан һәм пычрактан чистарту | М | 0,52 |
| Күперләрдә су үткәрү торбаларын кышка ябу һәм ачу (тампонажлау) | 1 торба | 450,48 |
| Тотынгычларны дымлы чүпрәк белән сөртү | М | 7,34 |
| Күпер корылмаларының су бүлү улакларын пычрактан һәм чүп-чардан чистарту | М | 177,10 |
| Күпер корылмаларының су кабул итү коеларын (басымны киметүче) пычрактан һәм чүп-чардан чистарту | Кое | 253,15 |
| Күпер корылмаларын кардан һәм боздан чистарту (боз чабу, боз сөңгеләрен вату) | Кв.м | 125,45 |
| Агымдагы карап тикшерү | | |
| Керү урыннары карап тикшерү | Кв.м | 0,26 |
| Күпер асты зонасын тикшерү | Кв.м | 0,03 |
| Күпер өслеген карап тикшерү | Кв.м | 0,21 |
| Аралык корылмаларны карап тикшерү | Кв.м | 0,86 |
| Терәк өлешләрен һәм терәк төеннәрен карап тикшерү | Терәк өлеше | 7,87 |
| Терәкләрне карап тикшерү | Данә | 7,87 |

| **Программа исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **Тариф, сумнарда** |
|---|---|---|
| Даими тикшерү | | |
| Керү урыннары карап тикшерү | Кв.м | 1,00 |
| Күпер асты зонасын тикшерү | Кв.м | 0,50 |
| Күпер өслеген карап тикшерү | Кв.м | 0,80 |
| Аралык корылмаларны карап тикшерү | Кв.м | 1,29 |
| Терәк өлешләрен һәм терәк төеннәрен карап тикшерү | Терәк өлеше | 25,74 |
| Терәкләрне карап тикшерү | Данә | 69,37 |

_______________